ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2025**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**214**

Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законына, 1996 елның 12 январендәне «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карарына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2025 елның 1 февраленнән 9 165,37 8 370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтада каралганча.
2. 2025 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 31 гыйнварындагы 193 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга .
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
214 номеры карарына
1 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән ТР Зеленодольск шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| **Хезмәтләр күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда )** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2.  Мәетне җирләү өчен табут һәм башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 4 994,68 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 1 422,81 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү | 2 747,88 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
214 номеры карарына
2 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән ТР Зеленодольск шәһәрендә
җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге бәяләре

| **Хезмәтләр күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда )** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Гыйбәдәт киеме кидертү/ Кәфенләү | 805,88 |
| 3. Мәетне җирләү өчен табут һәм башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 3 755,48 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 1 299,37 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 509,47 |
| **Барлыгы** | **8 370,20** |